СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» март, 2019 ел № 1

**«Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 нче маддәләренә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 60 нче номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә (1 нче Кушымта).

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлаулар оештыручысы итеп – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;
- үткәрү вакыты – 2019 елның 07 июне, сәгать 10.00 да;
- үткәрү урыны – Иске Чуриле авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- 2019 елның 06 июненә кадәр каралучы мәсьлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү адресы – Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чуриле авылы, Яна урамы, 52 нче йорт, Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Башкарма комитеты.

4. Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- гамәлдәге законнар буенча һәм әлеге карарда билгеләнгән вакыт аралыгында «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында йомгак ясарга һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проектны 2019 елның 06 апреленнән дә соңга калмыйча Интернет мәгълумати-телекоммуникация челтәрендә http://arsk.tatarstan.ru// веб-адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм http://arsk.tatarstan.ru// веб-адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чуриле авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Х.Гарифуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Иске Чуриле
авыл җирлеге Башлыгының
2019 елның «26» март
1 номерлы Карарына
1 нче Кушымта

**Проект**

**Арча муниципаль районы**
**Иске Чуриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«__» ________, 2019 ел №

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү максатыннан һәм 2018 елның 03 августындагы 340-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы, 2018 елның 03 августындагы 342-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законнарын гамәлгә ашырып, Иске Чуриле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кушымта буенча Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълумати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чуриле авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Х.Гарифуллин